**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**7 июнь, 2023 ел** **№ 301**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон чараларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» (алга таба – Нигезләмә) 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәне түбәндәге редакциядә «Судка кадәр шикаять бирү» яңа 5 нче бүлек белән тулыландырырга:

**«5. Судка кадәр шикаять бирү** [1]

5.1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында, алар фикеренчә, хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольдә тотылучы затлар, Контроль органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) һәм инспекторларның (алга таба шулай ук - вазыйфаи затлар) түбәндәге карарларына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль чаралар уздыру турында карарларына;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында контроль чаралар актларына, күрсәтмәләргә;

---

[1] Нигезләмә белән, муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, шикаять бирүнең судка кадәр тәртибе кулланылмый, дип билгеләнергә мөмкин, әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган (Федераль законның 39 статьясындагы 4 өлеше) контроль төре турында федераль законда, муниципаль контрольнең әлеге төрен оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр белән билгеләнмәгән булса.

3) контроль чаралар кысаларында вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына).

5.2. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан Контроль органына, Федераль законның 40 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очрактан тыш, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталларын кулланып, электрон рәвештә бирелә.

Граждан тарафыннан шикаять бирелгәндә, ул гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш. Шикаять оешма тарафыннан бирелгәндә, ул көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланырга тиеш.

Шикаятькә теркәлә торган материаллар, шул исәптән фото- һәм видеоматериаллар, контрольдә тотылучы зат тарафыннан электрон рәвештә тапшырыла.

5.3. Контроль орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять Контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) тарафыннан карала [2].

5.4. Шикаять, контрольдә тотылган зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып, утыз календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Контроль орган күрсәтмәсенә шикаять контрольдә тотыла торган зат күрсәтмәне алган вакыттан алып ун эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

5.5. Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаять биргән контрольдә торучы затның үтенечнамәсе буенча әлеге срок Контроль органы тарафыннан торгызылырга мөмкин.

5.6. Шикаять биргән контрольдә торучы зат, шикаять буенча карар кабул ителгәнче, аны кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шикаятьне шул ук нигезләр буенча кабат җибәрү рөхсәт ителми.

5.7. Шикаятьтә Контроль органының дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында үтенеч булырга мөмкин.

5.8. Контроль орган җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча карар кабул ителә:

1) Контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып тору турында;

2) контроль органның дәгъвалана торган карарын үтәүне туктатып торудан баш тарту турында.

Кабул ителгән карар турында мәгълүмат шикаять биргән контрольдә торучы затка карар кабул ителгән вакыттан алып бер эш көне эчендә җибәрелә.

5.9. Шикаять үз эченә алырга тиеш:

1) Контроль органы исеме, карарына һәм (яисә) гамәленә (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелә торган вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

2) гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны (эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны) турында белешмәләр, я оешманың -

[2] Нигезләмә белән, шикаятьләрне карау өчен, аның вазыйфаи затлары арасыннан контроль органда коллегиаль орган (коллегиаль органнар) төзү (Федераль законның 40 статьясындагы 3 өлеше) каралырга мөмкин

контроль астындагы затның исеме, әлеге оешманың урнашкан урыны турында белешмәләр, я ышанычнамә реквизитлары һәм ышанычнамә буенча шикаять биргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шикаятьне карау вакытына үзара эшчәнлекне башкаруның теләгән ысулы һәм аның буенча карар алуның теләгән ысулы;

3) шикаять биргән контрольдә торучы затның хокукларын бозуга китергән яисә китерергә мөмкин булган Контроль органның шикаять белдерелә торган карары һәм (яисә) аның вазыйфаи затының гамәле (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) алар нигезендә контрольдә тотылган зат Контроль органының карары һәм (яисә) вазыйфаи затның гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгән нигезләре һәм дәлилләре. Контрольдә тотылган зат тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин;

5) шикаять биргән контрольдә торучы затның таләпләре;

6) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы билгеләнмәгән очракта, аңа карата шикаять бирелә торган контроль чараның бердәм контроль (күзәтчелек) чаралары реестрында исәпкә алу номеры.

5.10. Шикаятьтә Контроль органы вазыйфаи затларының йә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар һәм цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр булырга тиеш түгел.

5.11. Шикаятьне бирү контрольдә тотыла торган затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан, аңа тиешле хокук бирелгән очракта, «Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5.12. Контроль орган, шикаять алган көннән алып биш эш көне эчендә, шикаятьне караудан баш тарту турында карар кабул итә, әгәр:

1) Шикаять әлеге Нигезләмәнең 5.4 пунктында билгеләнгән шикаять бирү сроклары тәмамланганнан соң бирелгән һәм шикаять бирүгә җибәрелгән срокны торгызу турында үтенечнамәне үз эченә алмый;

2) шикаять бирүгә үткәрелгән срокны торгызу турындагы үтенечне канәгатьләндерүдән баш тартылды;

3) аны биргән контрольдә торучы заттан шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр шикаятьне кире алу турында гариза килде;

4) шикаятьтә куелган мәсьәләләр буенча суд карары бар;

5) элегрәк Контроль органга шул ук контрольдә тотыла торган заттан шул ук нигезләрдә башка шикаять бирелгән;

6) шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы сүзләр, Контроль органы вазыйфаи затларының, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янау бар;

7) элек әлеге контрольдә тотыла торган затның шул ук предмет буенча шикаять белән кабат мөрәҗәгать итү мөмкинлеген юкка чыгарган шикаятьне караудан баш тарттылар һәм яңа дәлилләр яисә хәлләр китерелми;

8) шикаять тиешле булмаган органга бирелгән;

9) Россия Федерациясе законнарында Контроль орган карарларына шикаять белдерүнең суд тәртибе генә каралган.

5.13. Әлеге Нигезләмәнең 5.12 пунктының 3-8 бүлекләрендә күрсәтелгән

нигезләр буенча шикаятьне караудан баш тарту судка кадәр шикаять бирү нәтиҗәсе булып тормый һәм Контроль органы карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка шикаять белдерү өчен нигез була алмый.

5.14. Шикаятьне караганда, Контроль орган Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә судка кадәр шикаять бирүнең мәгълүмат системасын алып бару кагыйдәләре нигезендә контроль (күзәтчелек) эшчәнлегенә шикаять бирүнең мәгълүмат системасын куллана.

5.15. Шикаять контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан аны теркәгән көннән алып 20 эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.16. Күрсәтелгән срок түбәндәге аерым очракларда егерме эш көненә озайтылырга мөмкин:

1) гамәле (гамәл кылмавы) дәгъвалана торган вазыйфаи затка карата шикаятьтә күрсәтелгән фактлар буенча хезмәт тикшерүе үткәрелү;

2) гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата дәгъвалана торган вазыйфаи затның җитди сәбәп (авыру, отпуск, командировка) буенча булмавы.

5.17. Контроль орган шикаять биргән контрольдә торучы заттан шикаять предметына кагылышлы өстәмә мәгълүмат һәм документлар соратырга хокуклы. Контрольдә тотылучы зат күрсәтелгән мәгълүматны һәм документларны сорату җибәрелгәннән соң биш эш көне эчендә тапшырырга хокуклы.

Шикаятьне карау срогы барышы шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат бирү турында гарызнамә һәм документлар җибәрелгәннән алып аларны вәкаләтле орган алган мизгелгә кадәр, әмма сорату җибәрелгән вакыттан алып биш эш көненнән артык булмаган вакытка туктатып торыла.

Контрольдә торучы заттан шикаять предметына караган өстәмә мәгълүмат һәм документларны алмау шикаятьне караудан баш тарту өчен нигез булып тормый.

5.18. Шикаятьне биргән контрольдә тотылучы заттан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки аларга буйсынучы оешмалар карамагында булган мәгълүматны һәм документларны соратып алу рөхсәт ителми.

Шикаять биргән зат шикаять буенча йомгаклау карары кабул ителгәнче үз теләге белән шикаять предметына караган өстәмә материалларны тәкъдим итәргә хокуклы.

5.19. Кабул ителгән карарның законлылыгын һәм (яисә) башкарылган гамәлнең (гамәл кылмауның) нигезлелеген раслау бурычы Контроль органына йөкләнә.

5.20. Шикаятьне карау йомгаклары буенча Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыра;

2) Контроль орган карарын тулысынча яисә өлешчә юкка чыгара;

3) Контроль орган карарын тулысынча юкка чыгара һәм яңа карар кабул итә;

4) Контроль органы вазыйфаи затларының гамәлләрен (гамәл кылмавын) законсыз дип таный һәм асылы буенча, шул исәптән кирәк булганда, билгеле бер гамәлләрне башкару турында карар чыгара.

5.21. Контроль органның кабул ителгән карарны нигезләүне, аны үтәү срогын һәм тәртибен үз эченә алган карары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталында

контрольдә тотылучы затның шәхси кабинетында кабул ителгән көненнән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.»

1.2. Нигезләмәгә 3 нче кушымтаның «Индикатив күрсәткечләр» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Муниципаль торак контроленең индикатив күрсәткечләре исемлеге**

1) хисап чорында уздырылган планлы контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
2) хисап чорында уздырылган планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;
3) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга контроль объектының туры килүен, яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читкә тайпылуын ачыклау нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
4) хисап чорында үзара хезмәттәшлек белән үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;
5) хисап чорында үзара хезмәттәшлек белән КНМның һәр төре буенча уздырылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;
8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;
9) хисап чорында алар нәтиҗәсендә мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
10) хисап чорында алар нәтиҗәсендә административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;
11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;
12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
13) хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тартылган контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;
14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;
15) хисап чоры ахырына куркынычлык категориясенә кертелгән исәпкә алынган контроль объектларының һәр куркынычлык категориясе буенча саны;
16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затларның саны;
17) хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары уздырылган исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;
18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәр тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында, аларны карау йомгаклары буенча контроль (күзәтчелек) органы карарын тулысынча йә өлешчә юкка чыгару турында, яисә контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлгә яраксыз дип тану турында карар кабул ителгән судка кадәр тәртиптә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан бирелгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан контроль (күзәтчелек) органнары вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәгъва белдерү турында суд тәртибендә җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында алар буенча күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән контрольдә тотылучы затлар тарафыннан суд тәртибендә контроль (күзәтчелек) органнары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында дәгъвалар саны;

23) хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип табылган һәм (яисә) юкка чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районы рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

3. Нигезләмәнең 5 бүлеге әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Биектау муниципаль районы Башлыгы — Р. Ф. Хисамутдинов